| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2017ел 7 февраль** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 183** |

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Торак-2017» янгын сүндерү–профилактика операциясен үткәрү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент» 123–ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 елда Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Торак-2017» янгын сүндерү-профилактика операциясе үткәрергә.

2. Торак фондта янгын сүндерү-профилактика һәм агитация эшләре алып бару өчен түбәндәге составтагы оператив профилактик төркемнәр төзергә:

2.1. Зеленодольск шәһәре өчен:

- «ТР ЗМР Торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе (килешү буенча),
- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ җитәкчесе (килешү буенча),
- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча),

ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге башлыгы (килешү буенча),

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлегенең участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгы (килешү буенча),
- «ТР буенча 8 ФПС отряды» ФГКУ башлыгы (килешү буенча),
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлеге башлыгы;
- опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы,

Бөтенроссия ирекле янгын сүндерү җәмгыятенең Татарстан республика бүлекчәсенең (ТРО ВДПО) Зеленодольск районара бүлеге җитәкчесе(килешү буенча),

- «Зеленодольскгаз» ЭПУ башлыгы (килешү буенча),
- «Жилэнергосервис - Зеленодольск» ҖЧҖ һәм торак фондында электр хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче башка оешмалар башлыгы (килешү буенча),

2.2. Шәһәр (авыл) җирлекләрендә:

- җирлек администрациясе яисә башкарма комитеты вәкиле,
- «ТР ЗМР ТКХ департаменты» МБУ (җирлекләр территориясендә хезмәт күрсәтүче оешма) вәкиле (килешү буенча),
- «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» МКУ (килешү буенча),
- социаль өлкә хезмәткәре (килешү буенча),
- ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге хезмәткәре (килешү буенча),

Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәре (килешү буенча),

- «ТР буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 8 нче отряды» ФДУ хезмәткәре (килешү буенча),
- «Татарстан Республикасының янгыннан саклау» дәүләт казна учреждениесе(филиал) - янгынга каршы хезмәтнең Зеленодольск отряды аерым бүлекчәсе хезмәткәре (килешү буенча),
- Бөтенроссия ирекле янгын сүндерү җәмгыятенең Татарстан республика бүлекчәсенең (ТРО ВДПО) Зеленодольск районара бүлеге хезмәткәре (килешү буенча),
- «Зеленодольскгаз» ЭПУ хезмәткәре (килешү буенча),
- җирлекләрнең торак фондында электр хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче оешма хезмәткәре (килешү буенча);

3. «ТР ЗМР ТКХ департаменты» МБУ җитәкчесенә, Васильево штп., Карамалы Тау штп.,Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге белән берлектә оператив профилактик төркемнәр эшен оештырырга;

3.2. янгынга чыдамлыгы түбән булган күпфатирлы (барак тибындагы) торак йортларны (янгынга чыдамлыгы түбән булган 4,5 дәрәҗә), шәхси йорт хуҗалыкларын, коридор тибындагы йортларны, шулай ук янгынга чыдамлыгы түбән булган күпфатирлы торак йортларны исәпкә алырга һәм «Торак–2017» операциясе барышында күрсәтелгән йортларда гражданнар белән профилактика эшен оештырырга;

3.3. профилактик төркемнәр эшенең нәтиҗәләре буенча күп балалы гаиләләрнең, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнарның, халыкның социаль яктан имин булмаган катламнарының һәм әхлаксыз тормыш алып баручы кешеләрнең, шулай ук билгеле бер яшәү урыны булмаган кешеләрнең яшәү урыннары исемлеген төзәтергә. Газ һәм электр энергиясе өзелгән гаиләләрнең яшәү урыннарын аерым исәпкә алырга;

3.4. коммуналь хуҗалык учреждениеләре, торак пунктлар территориясендә урнашкан предприятиеләр көче белән, шулай ук социаль һәм спонсорлык ярдәме күрсәтү, депутатлар корпусын һәм эшмәкәрләрне җәлеп итү хисабына югарыда санап үтелгән категориядәге гражданнарның торак йортларында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен тупас бозуларны бетерүне оештырырга(күпбалалы һәм ялгыз картайган гражданнарга газ тоташтыру, җылылык мичләрен ремонтлау һәм электр үткәргечләрен ремонтлау өлешендә социаль ярдәм күрсәтү мөмкинлеген карарга);

3.5.әхлаксыз тормыш алып баручы ата-аналар тарафыннан куркынычсыз яшәү шартлары тәэмин ителмәгән очракта, янгында балаларның һәлак булуын кисәтү максатыннан, тиешле органнарга ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яисә чикләү турында тәкъдимнәр кертергә;

3.6. хезмәт күрсәтүче оешмалар белән берлектә янгын сүндерү гидрантларының, янгынга каршы су белән тәэмин итүнең башка чыганакларының һәм аларга килү юлларының төзеклеген, шулай ук аларны кар һәм боздан вакытында чистартуны тәэмин итәргә;

3.7. гражданнарга көнкүрештә, мич, газ һәм электр җиһазларын эксплуатацияләгәндә янгын куркынычсызлыгы чараларын җиткерер өчен күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге һәм хезмәт күрсәтүче оешмалар белгечләрен чакырып, барлык торак пунктларда гражданнар җыеннары үткәрергә;

3.8. янгыннан ешрак интегүче торак пунктларда (янгыннар саны арткан торак пунктларда) гражданнар белән өстәмә ишегалды буенча карап йөрүләр һәм җыеннар (очрашулар) оештырырга;

3.9. почта элемтәсе, торак оешмалары, халыкны социаль яклау хезмәткәрләре, полиция участок вәкаләтлеләре, ирекле янгын сүндерү җәмгыяте әгъзалары мөмкинлекләрен кулланып, халык арасында янгынга каршы тематикага агитация һәм пропаганда материаллары (белешмәләр, мәгълүмат битләре) таратуны оештырырга;

3.10.торак пунктларда торак фондының янгынга каршы торышы турында мәгълүматны гомумиләштерүне һәм анализлауны оештырырга, һәр айның соңгы сишәмбесендә ЗМР Башкарма комитетына ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге аша башкарылган эш турында (кушымта нигезендә) электрон документ әйләнеше системасы аша күрсәтелгән эшләр турында докладны Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә, Р. Р. Ардыхановка яки e-mail: ogpn-zmr@yandex.ru (Сибгатуллин Л.Г.) тапшырырга,

4. ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге башлыгына, ТР буенча 8 нче федераль янгын сүндерү-коткару отряды башлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә :

4.1. оператив профилактик төркемнәр белән методик дәресләр үткәрүне оештырырга, аларда торак сектор биналарына һәм корылмаларына куела торган янгын куркынычсызлыгының төп таләпләрен һәм профилактик чаралар үткәрү тәртибен аңлатырга, шулай ук күрсәтелгән төркемнәрне көнкүрештә гражданнарның янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү буенча белешмәлекләр белән тәэмин итәргә;

4.2.җирлек башлыкларына профилактик эш үткәрүдә һәрьяклап ярдәм күрсәтергә, шул исәптән оператив профилактик төркемнәрдә эшләү өчен белгечләр бүлеп бирүдә;

4.3. гражданнарның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча җыеннарын үткәрүдә катнашырга.

5. ЗМРда ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге начальнигына шәһәр (авыл) җирлекләре башлыклары соравы буенча оператив профилактика төркемнәре эшендә катнашу һәм торак пунктларда һәм социаль өлкә учреждениеләрендә аңлату эшләре алып бару өчен хезмәткәрләрне җибәрергә тәкъдим итәргә.

6. «Зеленодольск муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесенә, ТКХ хезмәт күрсәтү оешмалары җитәкчеләренә:

6.1. җирлек башлыклары соравы буенча оператив профилактик төркемнәр составында эшләү өчен тиешле белгечләрне җибәрергә;

6.2. йорт идарәчеләре һәм хезмәт күрсәтүче оешмалар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә янгыннарны кисәтү эшен оештырырга;

6.3. капиталь һәм агымдагы ремонт кысаларында янгынга каршы чараларны үтәү өчен акча җыю мәсьәләсе буенча күпфатирлы йортларда яшәүчеләрнең гомуми җыелышларын үткәрүне оештырырга;

6.4. гражданнарның яшәү урыны буенча көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларына укытуны, халык арасында агитация һәм пропаганда материаллары әзерләүне һәм таратуны оештырырга;

6.торак фондта, подвал һәм чорма бүлмәләрендә, коридорларда һәм күп фатирлы торак йортларның баскычларында электр челтәрләрен эксплуатацияләгәндә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә.

7. «ЗВКС» АҖ генераль директорына, үз балансында тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары булган предприятие җитәкчеләренә күрсәтелгән су белән тәэмин итү чыганакларын төзек хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрергә, аларның сафтан чыгуына юл куймаска, аларны вакытында ремонтларга һәм кардан һәм боздан чистартырга тәкъдим итәргә.

8. Бөтенроссия ирекле янгын сүндерү җәмгыятенең Татарстан республика бүлекчәсенең (ТРО ВДПО) Зеленодольск районара бүлеге директорына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

8.1. торак фондында янгыннарны профилактикалауда һәм гражданнар белән аларның көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы буенча эшләүдә актив катнашырга;

8.2. торак фондында төтен чыгару һәм вентиляция каналларын профилактик тикшерү һәм чистартуны тәэмин итәргә;

8.3. торак фондының мич һәм вентиляция җиһазларына хезмәт күрсәтүче предприятиеләр персоналы өчен янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча өстәмә укулар һәм инструктажлар үткәрүне оештырырга;

8.4. халыкның социаль яклanмаган катламнарына ягып җылыта торган мичне ремонтлау буенча адреслы ярдәм күрсәтергә.

9. ЗМР Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага барлык белем бирү учреждениеләрендә

укучылар һәм аларның ата-аналары белән көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы мәсьәләсе буенча методик дәресләр үткәрүне оештырырга.

10. Иҗтимагый оешмалар, дини конфессияләр вәкилләренә дини хезмәтләр һәм башка чаралар үткәрү барышында халык арасында янгын-профилактика эшен оештырырга тәкъдим итәргә, көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларын җиткерергә һәм халык арасында агитация һәм пропаганда материаллары таратырга.

11. «Зеленодольскгаз» ЭПУ, «Жилэнергосервис - Зеленодольск» ҖЧҖ һәм башка хезмәт күрсәтүче торак фонды (электр хуҗалыгы һ.б.) җитәкчеләренә җылыту системаларын ремонтлау, иске электр үткәргечләрен алыштыру буенча халыкның социаль якланмаган катламнарына адреслы ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

12. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына түбәндәгеләрне оештырырга тәкъдим итәргә:

12.1.халыкка торак сектордагы янгыннарның оператив хәле һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүмат бирү;

12.2.һәр янгын фактын, шулай ук көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматны булган массакүләм мәгълүмат чаралары аша яктыртырга;

12.3. массакүләм мәгълүмат чараларында торак фондының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә үткәрелә торган чараларны һәм проблемалы мәсьәләләрне яктырту;

12.4.әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының (http: zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

13. «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Торак-2016» янгын-сүндерү профилактика операциясен уздыру турында» 2016 елның 29 гыйнварындагы 217 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

14. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин